КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 3 июнь г.Казань № 769

VK Fest 2026 музыкаль фестивален уздырганда Казан шәһәре чикләрендә су объектларыннан файдалану турында

Россия Федерациясе Су кодексының 6 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, VK Fest 2026 музыкаль фестивален уздырганда кешеләрнең тормыш иминлеген тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елның 7 июнендә 14 сәгать 00 минуттан 22 сәгать 00 минутка кадәр Казансу елгасының «Миллениум» күпереннән алып Кремль дамбасына кадәр участокта азсыешлы судноларны, шулай ук җилкәнле, ял итү, спорт судноларын (гидроциклларны, байдаркаларны, ишү көймәләрен кертеп) куллануны тыюны (алга таба – тыю) билгеләргә.

2. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетына халыкка тыю турында, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша мәгълүмат бирү эшен оештыруны тәкъдим итәргә.

3. Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә тыюны үтәү максатларында көчләрнең һәм чараларның кизү торуын тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин